№ 22 (1149), 26 май 2012 ел

белән шөгыльләнүне тыйган, сихерчеләрне һәм сихер ясатучыларны ләгънәтләгән. Кешеләр һәм җеннәрнең яшәү урыннары, яшәү шартлары да аермалы. Кешеләр бу рәвешле җеннәр белән элемтәгә керергә ирешсәләр дә, аннан соңгы барышларда контрольне үз кулларында тота алмаска мөмкиннәр. Шуңа күрә иң яхшысы бу эшләргә катышмау зарур. Фал ачу һәм багучылык турында да берничә сүз әйтеп китик. Аллаһы: *"Әй ышанучылар, исерткеч эчемлек, кәрт уены һәм фал уклары - шайтанның эше булган начар гамәлләр. Алардан ерак торыгыз һәм котылуга ирешерсез",* – дип боерып бу вәзгыятькә ишарәт итә.

Күзгә күренмәүче мәхлуклар, затлардан тагын берсе – шайтан. Шайтанның Коръән-Кәримдә узучы исемнәреннән берсе - иблис. Шайтан - начарлык символы. Даими рәвештә кешеләрне тугры юлдан чыгарырга тырыша. Күп очракта кешеләрнең башкарган эшләрен үзләренә матур итеп күрсәтеп, аларны дөрес юлдан яздыруга ирешә. Шайтан кешеләр арасында дошманлык барлыкка китерү, аларның араларын бозу, кешеләрне яхшы эшләр башкарудан читләштерү өчен тырыша. Бу вәзгыятьтә янә Аллаһыга сыену, аның юлыннан чыкмаска тырышу зарур. Аятьләрдә: *"Ышанучыларга һәм Раббыларына таянучыларга шайтанның көче җитмәс. Аның көче бары тик шайтанны дус күрүче һәм Аллаһыны башка әйберләр белән тиңләштерүчеләргә генә җитәр",* - дип боерылып, бу вәзгыятькә ишарәт ителә. Коръән-Кәримдә: *"Әй кешеләр, җир йөзендәге хәләл ризыкларны ашагыз. Шайтанның адымнарына иярмәгез. Чөнки ул сезнең ап-ачык дошманыгыз",* - дип кешеләр шайтанга иярү мәсьәләсендә кисәтелә.

Мөхәммәд Пәйгамбәрнең начарлыклардан Аллаһыга сыену максаты белән бик еш кабатлаган һәм мөэминнәргә укырга киңәш иткән "Фәләкъ" һәм "Нәс" сүрәләренең мәгънәләре түбәндәгечә.

"Фәләкъ" сүрәсе: *"Әйт син аларга: яралтылганнарның мәкереннән, дөм караңгы төннәрдәге мәкердән, ырым төеннәренә өреп-өшкереп төкерүчеләрнең мәкереннән, көнчел вә хөсетле кешенең мәкереннән Аллаһыга сыенамын".*

"Нәс" сүрәсе: *"Әйт син: кешеләрнең Раббысына сыенамын. Кешеләрнең Алласына, кешеләрнең илаһына, шайтанның мәкерле котыртуыннан, кешеләрнең күңеленә вәсвәсә салучы шайтаннан, (ул шайтан) җен токымыннан булса да, кешеләрдән булса да (Аллаһыга сыенамын)".*

**Рәмзия ӘГӘ.**

*("Иман" газетасыннан)*

# Дуслар хакында хәдисләр

*"Кеше үз дустының динендә булыр, шуның өчен ул үзенә дус булачак кешенең холкын белсен!»*

Мөселман кеше үзенә дус-ишне сайлаганда, үзенең иманына, тәкъвалыгына зыян китерми торганнарын сайларга тиеш. Бу мәсьәләдә ул зирәк булып, кеше кыяфәтле шайтан дуслардан ерак булырга тиеш.

Чыннан да, кеше үзенә туры килә торган кеше белән дус була. Шуңа күрә акыллы кеше ахмак белән, түбәнчелекле кеше тәкәббер белән, галим кеше надан белән, ихлас күңелле мөселман монафыйк белән һичкайчан дус була алмас. Дус буласы кешене яхшы итеп сынарга кирәк. Яман кеше белән дус булганчы, бернинди дусларсыз гомер сөрү яхшырак.

*«Мөселман кеше үзенең кардәшеннән киселеп өч көннән артык торырга тиеш түгел. Алар үпкәләшүләре сәбәпле, очрашкач та, һәрберсе үз ягына карап, ике якка китеп баралар. Аларның иң яхшысы – башлап сәлам биргәне булыр".*

*«Җиде төрле кешене Аллаһы Тәгалә кыямәт көнендә - Үз күләгәсеннән башка күләгә булмаган көндә – Үзенең рәхмәт күләгәсе астына кертер. Шуларның беренчесе – гадел имам, икенчесе – Аллаһы Тәгаләнең гыйбадәтендә үскән егет, өченчесе – калебе мәчетләргә бәйле кеше, дүртенчесе – Аллаһы ризалыгы өчен берберсе белән дус булган ике кеше, бишенчесе – дәрәҗәле һәм матур хатын тарафыннан зинага чакырылган вакытта: "Мин Аллаһы Тәгаләдән куркам!" – дип, шул хатынның чакыруын кире каккан ир, алтынчысы – хәтта уң кулы биргәнне сул кулы белә алмаслык итеп, яшерен рәвештә садака бирүче кеше, җиденчесе – Аллаһы Тәгаләне аулакта зекер итеп, күзләре яшь белән тулган кеше».*

*«Дустыңны уртача ярат, чөнки ул беркөнне синең дошманыңа әйләнергә мөмкин. Дошманыңны да уртача дошман тот, чөнки ул беркөнне синең дустыңа әйләнергә мөмкин».*

Кемне дә булса дус итеп тотсаң, аны үзеңә сакланып дус ит, чөнки беркөнне берберегезгә ачуланышып, аерылышырга туры килер дә, шул вакытта элек аңа сөйләгән эч серләрең өчен оялып калырга һәм аны эчкерсез дус итеп йөргәнең әрәмгә китәргә мөмкин. Дошманың белән дә саклану һәм тигезлек саклап мөгамәлә кыл. Чөнки беркөнне шул ачуланышкан кеше белән дуслашырсың да, элек аның белән артык кырыс булганыңа үкенерсең. Кыскасы, үзеңә дус булган кешегә эчеңдәге бар серләреңне сөйләп бетермә, дошманыңны да бик каты кимсетмә.

*«Гадел, яхшы дус – ислемай сатучыга, ә начар иптәш тимерче күреген өрдерүчегә тиң. Ислемай сатучы янында булсаң, син аннан ислемай сатып алачаксың, яки, бер дә булмаса, сиңа аннан килгән хуш ис сеңәчәк. Күрек өрдерүчегә килгәндә исә, ул яки синең*





*ярлыкануын һәм аңа ныгытылуын сорагыз. Чынлыкта, хәзер аннан сорау алына».* Госман бине Гаффан әйтүенчә, *«Пәйгамбәр галәйһиссәлам сәхабәләргә бу сүзне мәет җирләгәннән соң әйтә торган булган».*

Садака бирүнең савабы мәеткә ирешүенә дәлил. Бер кеше Пәйгамбәр галәйһис-сәлам янына килеп сораган: *«Әй Аллаһының Илчесе, минем әнием кинәт үлеп китте һәм васыятен әйтмәде, әйткән булса, садака бирергә кушар иде, дип уйлыйм. Мин аның өчен садака бирсәм, аңа савап булачакмы?»* Пәйгамбәр галәйһиссәлам: *«Әйе»,* – дигән.

Ураза тотуның савабы мәеткә ирешүенә дәлил. Гайшә анабыз Пәйгамбәр галәйһиссәламнең әйткәнен сөйләгән: *«Кемдер үлеп китеп, өстендә ураза калса, вәлие аның өчен уразасын тотсын».*

Әбү Хәнифә Ибне Габбас китергән хәдисенә таянып, *«Мәет өчен ураза тотарга ярамый»,* – дигән. Мәетнең калган уразасының һәр көне өчен кешеләрне ашату тиеш дип санаган.

Хаҗ кылуның савабы мәеткә ирешүенә дәлил. Ибне Габбас әйткән: *«Бервакытны Җүһәйнә кабиләсеннән бер хатын Пәйгамбәр галәйһиссәлам янына килеп: «Әнием хаҗ кылырга дип нәзер иткән иде, хаҗ кылмыйча вафат булды. Мин аның өчен хаҗны үтимме?»* – дип сораган. Пәйгамбәр галәйһис-сәлам әйткән: *«Аның өчен хаҗны үтә. Әгәр әниең өстендә бурыч булган булса, бурычын түләр идеңме?! Ә Аллаһының хакы үтәлүгә күбрәк хаклы».*

Савап ул – эшләүченең эшләгәне өчен хасил булган хакы. Әгәр дә үзенең мөселман кардәшенә үзе эшләгән хакын бүләк итә икән, исән вакытында аңа мал бүләк итүдән тыелмаган сыман, бу да тыелган эш түгел. Кардәше вафат булганнан соң бурычын үтәү дә шулай ук санала.

Аллаһы Тәгалә ураза һәм Коръән уку кебек тән гыйбадәтләренең савабы үлгәннәргә барып ирешүен безгә белдергән. Ураза ул – уразаны бозучы нәрсәләрдән ниятләп тыелып тору, ә Коръән уку – гамәл белән ният.

Коръәнне укып, аның савабын багышлау ураза һәм хаҗ саваплары ирешкән сыман мәеткә ирешә. Әмма бу эш элеккеге галимнәрдә булмаган һәм Пәйгамбәр галәйһис-сәлам моны кушмаган. Элеккеге галимнәрнең моны эшләмәүләре савапның ирешмәвенә дәлил түгел.

Пәйгамбәребез галәйһис-сәламнең моны кушмыйча, ураза һәм хаҗга рөхсәт бирүенә килгәндә, ураза һәм хаҗ турында хөкемне Пәйгамбәр галәйһис-сәлам үзе башлап чыгармаган, фәкать бирелгән сорауга җавап кына кайтарган: берсе үлгән кеше урынына хаҗ кылуга рөхсәт сорагач, рөхсәтен биргән; икенчесе ураза турында сорагач, моңа да рөхсәт иткән һәм башкасыннан тыймаган.

Шулай булгач, ризыктан, башкалардан тыелу һәм нияттән гыйбарәт ураза тоту белән эш һәм нияттән гыйбарәт Коръән укуның савабы ирешүе арасында аерма юктыр.

*(«Дин вә йола" газетасыннан)*




**- Җомга көнне без, хатын-кызлар, намазны өйдә укыйбыз. Җомга вакытында өйлә намазын укырга ярыймы? Әллә җомга вакыты узгач укыргамы?**

- Җомга вакытында хатын-кызлар укымыйча торса - хәергә, дигән сүзләр йөри. Әмма аларны тыярга кемнең дә хакы юк. Догаларның кабул була торган вакыты бар, дигән сүзләр дә хактыр. Ул яңгыр яуган вакытта, азан белән камәт арасында, имам хөтбә сөйләгәндә кебек сүзләр дә бар. Шуңардан чыгып булса кирәк, азан-камәт арасы сузыла, чөнки имам хөтбә сөйли бит. Җомга намазын өйдә укучылар бераз сабыр итеп торсалар - хәерлерәк. Әгәр укысалар, намазлары кабул булмый, дияргә беркемнең дә хакы юк. Чөнки намаз вакыты кергән була бит.

**- Башка дин әһеле мәетен озатканны күргәндә аягүрә басаргамы, юкмы?**

**Кайчак урамда берничә кеше сөйләшеп утырганда мәетне соңгы юлга озатканнарын күрәсең. Безнең мөселман кешесен түгел, ә носари яки яһүд динендәгеләр мәетен озаткан очрак та була. Мондый чакта берәүләр әйтә: аягүрә басып озатып калырга кирәк, икенчеләре: бу мәҗбүри түгел, диләр. Мөселманнар бу очракта үзләрен ничек тотарга тиеш?**

- Бу турыда Коръәндә бер сүз дә юк. Без - мөселманнар - сөнниләр, мондый очракта Аллаһы илчесе - Пәйгамбәребез (с.г.в.) традицияләрен дәвам итәргә тиешле. Бу очракта хәдисләргә мөрәҗәгать итик: Мөхәммәд (с.г.в.) мондый очракларда нишләгән?

Имам әл-Бохари төзегән "Әл-Җәми ас-Сәхих" ("Дәлилләнгән хәдисләр мәҗмугасы") әсәрендә бу сорауга җавап булырлык ике хәдис теркәлгән.

Леуаз Б.Фидаль тапшырган: "Берчакны яныбыздан мәет күтәреп баручыларны күрдек. Пәйгамбәребез аякларына басты, без дә аңа иярдек. Ләкин: "Бу - яһүди мәет бит?" - дидек. Җавабында ул әйтте: "Һәр соңгы юлга озатылучыларны күрсәгез, аягүрә басыгыз!"

Икенче бер хәдис: "Бер тапкыр Сакль Б.Хунайф һәм Кайс Б.Сад әңгәмә корып утыралар иде. Бу Кадисиядә булды. Мәет күтәреп килгән җеназачыларны күргәч, алар торып бастылар. Кешеләр аларга: "Мәет - җирле кеше бит", - дигәч (ягъни алар яклавы астында яшәүче яһүд яки христиан), җавапка: "Бер тапкыр Пәйгамбәребез (с.г.в.) яныннан (Аллаһы аңа мәрхәмәт итсен) мәет озатучылар узып бара иде. Ул аягүрә басып калды. Аңа: "Бу яһүд мәете иде", - дигәч, Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: "Берәүнең җаны үтеп бара түгелме?" - диде.

*("Татар мөселман календаре"ннан)*